**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер, Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**«19» март 2016 ел** **№ 20.1**

**«2016 - 2018 елларга Яңа Кенәр авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программаны раслау турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2016-2018 елларга Яңа Кенәр авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын расларга.

2. Чараларны үтәүчеләргә «2016-2018 елларга Яңа Кенәр авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:\pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.

Арча муниципаль районы
Яңа Кенәр авыл җирлеге Башкарма
комитетының
19.03. 2016 ел, № 20.1 карары белән
РАСЛАНДЫ

**«2016 - 2018 елларга Яңа Кенәр авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программа**

Гомуми нигезләмәләр

Программаның төп максаты - Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү һәм шул нигездә халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, халыкны эш белән тәэмин итү, җитештерү, хезмәт һәм интеллектуаль потенциалны үстерү.

Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| 1. Муниципаль программа исеме | «2016 - 2018 елларга Яңа Кенәр авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программасы |
| 2. Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнар; 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасында |
| 3. Муниципаль программаның муниципаль заказчысы | Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. Муниципаль программаның төп максаты | - кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен уңайлы мохит булдыру;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлыкның гамәлдәге субъектларын саклап калуга һәм булдыруга ярдәм итү;<br><br>- базарны җирле җитештерүчеләр товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре белән баету;<br><br>- авыл җирлегендә яшәүче халыкны эш белән тәэмин итү. |

| | |
|---|---|
| 5. Муниципаль программаның төп бурычлары | Барлык дәрәҗәләрдә бизнес һәм хакимиятнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының (алга таба - Субъектлар) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның (алга таба - Оешманың) үзара хезмәттәшлеге рәвешләрен һәм механизмнарын үстерү һәм камилләштерү;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше мониторингы;<br><br>-кече һәм урта эшкуарлык турында уңай җәмәгать фикерен булдыру;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) алга җибәрүдә ярдәм күрсәтү. |
| 6. Муниципаль программаның төп чараларын үтәүчеләр | Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты. |
| 7. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2016-2018 еллар |
| 8. Муниципаль программа максатларына ирешү индикаторлары | - кече эшкуарлык субъектлары санын арттыру;<br><br>- өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр санын арттыру;<br><br>- җитештерү күләмнәрен үстерү, продукция сату базарын киңәйтү;<br><br>- җирлек территориясендә җитештерелгән товарлар төрләрен киңәйтү. |
| 9. Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | - җирлек бюджеты акчалары - 30 мең сум, |

## 1 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАРЫН ТАСВИРЛАУ

Кече эшкуарлык - икътисадый һәм сәяси тотрыклылык, иҗтимагый үсеш, товарларның яңа төрләрен үзләштерү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү өчен принципиаль әһәмияткә ия икътисадның өстенлекле секторы. Яңа Кенәр авыл җирлегендә 2016 елның 1 гыйнварына кече һәм урта эшкуарлыкның 31 субъекты эшчәнлек алып бара.

## 2 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ РЕАЛИЗАЦИЯСЕ

Программаны гамәлгә ашыру срогы 2016 елдан 2018 елга кадәр

## 3 нче бүлек. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ТАСВИРЛАУ

| № т/б | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты | Чараларны башкаручылар | Район бюджеты акчалары исәбеннән финанслау күләме (еллар буенча) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1 елы | 2 елы | 3 елы | Барлыгы |
| Муниципаль программаның максаты | | | | | | | |
| 1.1.Төп чара | | - товарларны, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне сату базарын киңәйтү максатларында күргәзмәләрдә һәм ярминкәләрдә катнашуга җирлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын җәлеп итү; | Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.2.Төп чара | | Дәүләт ярдәмен алу мәсьәләләре буенча җирлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен консультацияләр оештыру | Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.4 | | Уңайлы иҗтимагый климат тудыру максатында кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган | Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма | 2 т.б. | 2 т.б. | 2 т.б. | 6 т.б. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | конкурслар үткәрү һәм массакүләм мәгълүмат чараларында уздырыла торган чараларны яктырту. | комитет ы | | | | |

## 5 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА МАКСАТЛАРЫНЫҢ ИНДИКАТОРЛАРЫ

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | База нигезендә 2015 елның әһәмияте | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның беренче елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның беренче елы | 3 ел Муниципаль программа |
|---|---|---|---|---|---|
| - кече эшкуарлык субъектлары санын арттыру; | Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны | 10 | 2 | 3 | 4 |
| - өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр санын арттыру; | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан бирелгән эш урыннары саны | 15 | 5 | 6 | 7 |
| - җирлек территориясендә җитештерелгән товарлар төрләрен киңәйтү. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары җитештергән товарларның төрләре саны | 8 | 4 | 5 | 6 |

## 6 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

| Финанслау чыгнаклары | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 елы программ аны гамәлгә | 2 елы . программа | 3 ел программа ны гамәлгә | муниципаль программаны гамәлгә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ашыруның | ны гамәлгә ашыруның | ашыруның | ашыруның программаны гамәлгә ашыруның |
| Җирле бюджет | 10 мең сум. | 10 мең сум. | 10 мең сум. | 30 мең сум. |

Программаның чараларын финанслау авыл җирлеге бюджеты исәбеннән башкарыла.

Программаны 2016 елда финанслауның гомуми күләме - 2018 елларда 30 мең сум тәшкил итә.

Бюджет акчалары күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле бюджетлар проектларын төзегәндә һәм караганда билгеләнгән тәртиптә ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.